ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.09.2019 № 1402/2

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен килешү төзү хокукына бәйге үткәрү тәртибе турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 нчы елның 27 нче июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнын гамәлгә ашыру максатларында, «Реклама турында» 2006 нчы елның 13 нче мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 нчы маддәсенең 5.1 пункты, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсе нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 нче елның 27 нче февралендәге "Муниципаль учреждениеләр һәм АМР җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе Нигезләмәсен раслау турында"гы 149 нчы номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен килешү төзү хокукына бәйгенең заказчысы итеп Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына конкурсны оештыручы функцияләрен башкару вәкаләтен бирергә.

3. Расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен килешү төзү хокукына бәйге үткәрү комиссиясе турында Нигезләмә (1 нче кушымта нигезендә);

3.2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен килешү төзү хокукына бәйге үткәрү турында Нигезләмә (2 нче кушымта нигезендә);

3.3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен килешү төзү хокукына бәйге үткәрү турында хәбәр итүнең типлаштырылган формасы (3 нче кушымтада).

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамыгымда калдырам.

Җитәкче в.б. Л.Ф. Нургаянов